**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**

**Министерство образования Республики Мордовия**

**Ромодановский муниципальный район**

**МБОУ "Белозерьевская средняя общеобразовательная школа"**

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
|---|---|---|
| Методобъединение | Зам.директора по УВР | Директор школы |
| ________________________ | ________________________ | ________________________ |
| Савинова М.Н. | Манеева Л.Р. | Киреева Э.И. |
| Протокол №1 от «31» августа2023 г. | Протокол №1 от «31» августа2023 г. | Приказ № 93 от «31» августа2023 г. |

Рабочая программа

учебного курса «Родной (татарский) язык» в 6 классе ФГОС

Составитель:
Курмаева Х. А.
учитель родного языка
и литературы
МБОУ «Белозерьевская СОШ»

с. Белозерье, 2023 год

# Аңлатма язуы

**Эш программасы статусы**

Программа нигезенә Россия, Татарстан Мәгариф һәм фән министрлыкларының мәктәпләрдә урта һәм тулы белем алу стандартлары салынды, ТР Мәгариф министрлыгы тарафыннан расланган «Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары» (Казан, «Мәгариф», 2003 ел).

**Эш программасы структурасы**

Татар теленең эш программасы өч өлештән тора: аңлатма язуыннан, төп бүлекләрне, белем һәм күнекмәләрне үз эченә алган программаның эчтәлегеннән, укучыларның әзерлек дәрәҗәсенә таләпләреннән.

**Эш программасының эчтәлеге**

***Рус мәктәбендә белем алучы татар балаларына татар теле укытуның төп максаты һәм бурычлары***

- татар телен өйрәнүгә карата башлангыч сыйныфларда нигез салынган кызыксынуны көчәйтү, үз милләтеңә, теленә хөрмәт белән карау хисе тәрбияләү;
- татар теленең барлык тармаклары буенча эзлекле рәвештә фәнни белем бирү;
- сөйләм эшчәнлеге төрләре буенча ныклы күнекмәләр булдыру. Туган телдә матур һәм дөрес аралашырга өйрәтү;
- телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү;
- телне өйрәнгәндә үзләштергән белем һәм күнекмәләрне гомәлдә дөрес куллана белү;
- укучыларны даими рәвештә татар милли мәдәнияте мирасына тарту;
- халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү, укучыларның татар телен өйрәнүгә ихтыяҗын арттыру.

***Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы***

**Коммуникатив компетенция.** Сөйләм. Телдән һәм язма сйләмне аеру. Аралашу ситуациясенә бәйле рәвештә телдән һәм язма сөйләмне дөрес файдалану. Сөйләм эшчәнлеге төрләрен (тыңлап аңлау, сөйләү, уку һәм үзләштерү). Текстның эчтәлеген кыскача, тулы яки сайлап алып сөйләү. Диктантлар, изложениеләр һәм сочинениеләр язу.

**Лингвистик компетенция.** Матур әдәбият һәм аның нормалары турында төшенчә. Тел белеменә караган сүзлекләр һәм алардан файдалану. Фонетика һәм орфоэпиядән алган белем һәм күнекмәләрне гамәлдә куллану. Лексикологиядән алган белем һәм күнекмәләрне гамәлдә куллану. Морфологиядән алган белем һәм күнекмәләрне гамәлдә куллану.

## Укыту программасының үзләштерелүен тикшерү

1. Дәреслектәге «Белемегезне тикшерегез» биремнәре
2. “Мәгариф” журналындагы контроль эшләр, тестлар һәм диктантлар

## Класстан тыш эшләр

- Фонетик КВН;
- “Лексика дөньясына сәяхәт”;
- Фольклор кичәсе;
- Кичә дәрес «Без татарлар, туган телебез – татар теле»;
- Телләр атналыгына лингвистик газета чыгару

## Укыту-методик комплекты

1. Рус мәктәпләрендә укучы татар балаларына ана теле һәм әдәбият укыту программалары. Казан. «Мәгариф» нәшрияты. 2015);
2. Рус мәктәпләрендәге татар балаларына татар теленнән гомуми белем бирүнең дәүләт стандарты (Казан, 2005);
3. Р.К.Сәгъдиева, Р.М.Гарәпшина Татар теле. Казан. Мәгариф-Вакыт. 2015

## Тематик план

| Т/с | № т/с | Бүлекләр һәм темалар | Сәгать саны | Үткәрү вакыты | | Үзләштерелергә яки камилләштерелергә тиешле махсус белем һәм күнекмәләр | Контроль төре | Искәрмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | Туган тел турында әңгәмә | 1 | тиеш | үтелде | "Ин матур тел - туган тел, Әнкәм сөйләп торган тел " темасына сөйләшү | Хикәя язу | БСҮ – 1 |
| **1. 5 нче сыйныфта үтелгәннәрне кабатлау** | | | | | | | | |
| .2 | | Җөмлә кисәкләре | 1 | | | Җөмләнең нигезе булган ия һәм хәбәр. Аларнын сораулары. Иярчен кисәкләр: аергыч, тәмамлык, хәл. Аергычның төп сыйфат, исем белән белдерелүе. Тәмамлыкның исем һүм исем урынында килгән башка сүз төркемнәре белән белдерелүе. Хәлнең, гадәттә, рәвеш, исем, фигыльләр белән белдерелүе. | | |
| 3. | | Тикшерү диктанты | 1 | | | | Диктант № 1 | |
| 4. | | Сүз ясалышы | 1 | | | Тамыр, ясалма, кушма сүзләрне аеру. Сүзнең төп мәгънәле кисәге тамыр булу. Ясалма сүзнең тамырга ясагыч кушымча кушылып ясалуы. Ике сүзнең кушылып бер мәгънә белдерүе кушма сүз булуы. | | |
| 5. | | БСҮ Изложение | 1 | | | | Изложение № 1 | БСҮ- 2 |
| 6. | | Сүз төркемнәре турында төшенчә | 1 | | | Морфология - тел белеменең сүз төркемнәрен өйрәнә торган бүлеге. Мәгънәләре һәм грамматик билгеләре буенча бер төркемгә берләштерелә торган сүзләрне суз төркемнәре дип атау. Телдә барлыгы 12 сүз төркеме булу. Аларның мөстәкыйль (исем, сыйфат, рәвеш, сан, алмашлык, фигыль, аваз ияртемнәре), бәйләгеч (бәйлек, теркәгеч), модаль (хәбәрлек сүз, ымлык, кисәкчә) сүз төркемнәренә бүленүе. | | |
| **ИСЕМ** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 7. | | Исем. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр | 1 | | | Исем - предметны һәм затларны белдереп, кем? нәрсә? сорауларына җавап бирүче сүз төркеме. Бер төрдән булган предметлар, затлар өчен уртак исемнәрнең уртаклык исем, бер төрдән булган предмет һәм затларның берсенә генә бирелгән исемнең ялгызлык исем булуы. | Сүзлек диктанты. (Ялгызлык, уртаклык исемнәр) | |
| 8. | | Мәкалә язу. "Без-табигать сакчылары" | 1 | | | | Мәкалә | БСҮ- 3 |
| 9. | | Исемнәрнең берлек-күплек саны | 1 | | | Исемнәрнең берлек һәм күплек санда килүе. Берлек саннын аерым күрсәткече булмау. Исемнәрнең күплек төренә -нар, -нәр -лар, -ләр кушымчалары ялгану. Ялгызлык исемнәрнең берлек санда гына кулланылуы. | Тәржемә итү | |
| 10 | | Исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | | | Исемнәрнең 6 килеше булуы. Баш килешнең кушымчасыз булуы, калган килешләрнең кыек килешләр дип аталуы. Килеш сораулары һәм кушымчалары.<br>Рус һәм татар телләрендә исемнәрне килешләр белән төрләндерүнең үзенчәлекләре. | Тәрҗемә итү | |
| 11. | | Сочинение | 1 | | | | Сочинение № 1 | БСҮ- 4 |
| 12. | | Исемнәрнең тартым белән төрләнеше | 1 | | | Исемнәрнең предмет , затның башка бер предметка, затка караганлыгын тартым кушымчалары аша белдерүе. Тартым кушымчаларының предмет яки затның сөйләүчегә (мин, без), тыңлаучыга (син, сез), сөйләмдә катнашмаган затка яки предметка (ул, алар) караганлыгын белдерүе. | | |
| 13. | | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнеше | 1 | | | Тартымлы исемнәрнең килеш белән төрләнешендәге үзенчәлекләр: тартымлы исем килеш белән төрләнгәндә, исемгә башта тартым кушымчасы, аннары килеш кушымчасы ялгану. | Тәрҗемә итү | |
| 14. | | Исемнәрнең ясалышы | 1 | | | Ясалышлары ягыннан исемнәрнең тамыр, ясалма, кушма, тезмә, кыскартылма, парлы булулары. Ясалма исемнәрнең ясагач кушымча ялганып ясалуы. Кушма исемнәрнең берничә сүзнең кушылуы нәтиҗәсендә | Сүзлек диктанты | |
| 15. | | Контроль Диктант | 1 | | | | Диктант №2 | |
| 15 сәг. | | | | | | | | |
| **2 ЧИРЕК** | | | | | | | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16. | | Исемнәрнен җөмләдә кулланылышы | 1 | | | Баш килештәге исемнең ия, хәбәр, тәмамлык, аергыч, хәл булып килә алуы. Җөмләдә иялек килешендәге исем - аергыч, төшем килешендәге исем - тәмамлык, юнәлеш, чыгыш, урын-вакыт килешләрендә килеп, кая? кайдан? кайда? сорауларына җавап бирүче исемнәрнен хәл булып килүе Җөмләләрне русчага тәрҗемә иткәндә җөмлә кисәкләренең үзгәрүе.. | | |
| 17. | | Диалог төзү | 1 | | | Юл йөрү кагыйдәләрен белүне күрсәткән диалоглар төзү. | Диалог | БСҮ- 5 |
| 18. | | Исемнәргә морфологик һәм морфологик-синтаксик анализ | 1 | | | Исемнәргә морфологик һәм морфологик-синтаксик анализ ясау тәртибен үзләштерү. | | |
| 19. | | Хат язу | 1 | | | Әти-әииенә яки туганнарына рәхмәт хаты язу. | | |
| **СЫЙФАТ** | | | | | | | | |
| 20.. | | Сыйфат турында төшенчә<br>Асыл һәм нисби сыйфатлар | 1 | | | Сыйфатның предметның билгесен белдереп, нинди? кайсы? кайдагы? сорауларына җавап бирүе. Аның исемне ачыклап килүе. Сыйфат ачыклаган исемнең сыйфатланмыш булуы. Сыйфатның җөмләдә күбрәк аергыч һәм хәбәр булып килүе.<br>Асыл сыйфатларның предметларның, кеше һәм хайваннарның төп билгеләрен белдерүе (кип елга, кыю кыз). Нисби сыйфатларның предметнын бүтән предметка, хәлгә, эшчәнлеккә мөнәсәбәтле билгесен белдерүе (балалар китабы, кичәге эш) | Иҗади диктант | |
| 21. | | Сочинение | 1 | | | | Сочинение №2 | БСҮ-6 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 22. | | Сыйфатларның ясалышы. | 1 | | | Сыйфатларның ясалышы буенча төрләре: тамыр, ясалма, кушма, парлы һәм тезмә сыйфатлар. Ясалма сыйфатларның күбрәк исем һәм фигыльләргә махсус кушымчалары ялганып ясалуы. Сыйфат ясагыч кушымчалар: -лы, -ле, -сыз, -сез, гы, -ге, -кы, -ке, -чан, -чән, -ык, -ек, -к, ынкы, -енке, -ма, -мә, -гыч, -геч, -лык, -лек.<br>Кушма сыйфатларның ике сүзне кушу ярдәмендә ясалуы.<br>Парлы сыйфатларның ике сүздән торуы, сызыкча аша язылуы.<br>Тезмә сыйфатларның берничә сүздән ясалуы, аерым язылуы.<br>Гарәп-фарсы, рус һәм башка телләрдән алынган сүзләрдән ясалган сыйфатлар. | | |
| 23. | | Сыйфат дәрәҗәләре | 2 | | | Татар телендә дүрт сыйфат дәрәҗәсе булуы. Гади дәрәҗәге сыйфатлар предметның гадәти (төп) билгесен белдерүе. Чагыштыру дәрәҗәсендәге сыйфатларның бер предметтагы билгенең башка предметтагы билге белән чагыштырганда, я бераз артыграк, я азрак булуын күрсәтүе {-рак, -рәк кушымчалары ялганып ясала).<br>Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфатларның бер предметтагы билгенең башка предметларга караганда күбрәк булуын белдерә. Артыклык дәрәҗәсенең сыйфатның бер иҗегенә җайлаштырылган көчәйткеч кисәкчәләр ярдәмендә; иң, утә, җете, дөм һәм башка кисәкчәләр белән; бер үк сыйфатны кабатлау аша ясалуы. | | |
| 24 | | Изложение (контроль) | 1 | | | Бирелгән текстның телен һәм стилен саклап яза белү | Изложение №2 | БСҮ-7 |
| 25. | | Сыйфатларның җөмләдә кулланылышы | 1 | | | Җөмләдә сыйфатларның, гадәттә, аергыч, хәбәр, хәл булып килүе. Сыйфатның сыйфатланмыштан алда килсә - аергыч, артта килсә - хәбәр, фигыльне ачыкласа, хәл булуы. | | |
| 26. | | Сыйфатларның исемләшүе. | 1 | | | Сыйфатланмыштан башка килгән исемнәрнең килеш һәм тартым белән төрләнүләре, берлек һәм күплек санда килүләре. Бу күренешнең сыйфатларның исемләшүе дип аталуы. | Диктант - 10 мин. | |
| 27. | | Диалогик сөйләм үстерү | 1 | | | "Кошлар - безнең дусларыбыз" темасы буенча сөйләшү | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 28. | | Сыйфатларны гомумиләштереп кабатлау | 1 | | | Сыйфатларга морфологик-синтаксик анализ ясый белү Тема буенча үтелгәннәрне кабатлау. | | |
| 29. | | Тикшерү Диктанты | 1 | | | | Диктант №3 | |
| 14 сәг | | | | | | | | |
| **3 чирек** | | | | | | | | |
| **САН** | | | | | | | | |
| 30. | | Сан турында төшенчә | 1 | | | Предметның санын, исәбен белдереп, ничә?купме? никадәр? ничәнче? ничәләп? ничәү? ничәшәр? сорауларының берсенә җавап булган сүз төркеменең сан дип аталуы. Җөмләдә санның күбрәк исемне ачыклап килүе, аергыч булуы. Сан белән ачыкланган сүзнең саналмыш булуы. Санның күбрәк цифрлар белән язып күрсәтелүе. Гарәп һәм рим цифрлары һәм аларны куллану. | | |
| 31. | | Диалог төзү | 1 | | | "Кибеттә" темасына диалог төзү | | |
| 32. | | Саннарның ясалышы | 1 | | | Ясалышлары буенча саннарның тамыр, кушма, парлы, тезмә төрләре булуы.<br>Тамыр саннарның бер кисәктән торуы.<br>Кушма саннарның кушылып язылуы.<br>Тезмә саннарның, тамыр саннардан төзелеп, аерым язылуы.<br>Парлы саннарның чама һәм бүлем төркемнәрендә генә очравы, сызыкча аша язылуы. | Тәрҗемә итү күнегүләре | |
| 33 | | Гарәп һәм рим цифрларының язы-лышы | 1 | | | Гарәп цифрларыннан сон килгән кушымчаларның аерым язылуы. Рим цифрларыннан сон килгән кушымчаларның язылмавы, сызыкчалар куелмавы. | | |
| 34. | | Сан төркемчәләре. Микъдар саны | 1 | | | Белдергән мәгънә төсмерләренә һәм формаларына карап, саннарның биш (микъдар (төп), тәртип, бүлем, чама, җыю) төркемчәгә бүленүе. Төп сан-нарның предметларның төгәл исәбен белдерүе һәм ничә? күпме? никадәр? сорауларына җавап булуы. Өлеш саннарының да шушы төркемгә керүе. | Диктант-10 мин | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 35. | | Диктант | 1 | | | | Диктант №4 | |
| 36. | | Тәртип саны | 1 | | | Тәртип санының предметларның саналу яки урнашу тәртибен белдереп, ничәнче? соравына җавап булуы. Төп санга -нчы, -нче, -ынчы, -енче кушымчалары кушылып ясалуы. Телеграмма язу үрнәге. | Хикәя язу. "Чаңгы ярышында" | |
| 37. | | Бүлем саны | 1 | | | Бүлем санының предметны тигез өлешләргә бүлүен белдереп, ничәшәр? күпмешәр? сорауларына җавап бирүе. Төп санга -ар, -әр, -шар, -шәр кушымчалары ялганып ясалуы. | Хикәя язу. "Чаңгы ярышында" | |
| 38. | | Чама саны | 1 | | | Чама санының предмет исәбен якынча, чама белән генә белдерүе, никадәр? ничәләп? сорауларына җавап бирүе. Төп санга -лап, -ләп, -ларча, -ләрчә, -нарча, -нәрчә, -лаган, -ләгән кушымчалары ялгап ясалуы. | | |
| 39. | | Җыю саны | 1 | | | Җыю санының бер төрдәге предметларның бергә туплану исәбен белдерүе, ничәү? күпме? сорауларына җавап булып килүе. | | |
| 40. | | Сочинение | 1 | | | | Сочинение №3 | БСҮ-8 |
| 41. | | Саннарның җөмләдә кулланылышы | 1 | | | Саналмышы белән килгән саннарның җөмләдә күбрәк аергыч булулары, төрләнмәве. Саналмышыннан башка килгән саннарның, исемнәр кебек, килеш һәм тартым белән төрләнүе, җөмләнең төрле кисәкләре булып килүләре. Математик гамәлләрдә кулланыла торган саннарның саналмышсыз килеп төрләнә алуы һәм җөмләнең төрле кисәге булуы. | | |
| 42. | | Саннарны кабатлау | 2 | | | Саннарга морфологик - синтаксик анализ ясый белү. | | |
| 43. | | Изложение | 1 | | | | Изложение №3 | БСҮ-9 |
| **РӘВЕШ** | | | | | | | | |
| 44. | | Рәвеш. Рәвеш турында тошенчә | 1 | | | Җөмләдә эш яки хәлнең билгесен белдереп, ничек? кая? кайда? кайдан? купме? никадәр? кебек сорауларның берсенә җавап бирә торган сүз төркеменең рәвеш дип аталуы. Рәвешнең күбрәк фигыльгә ияреп килүе. | | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 45. | | Рәвешләрнең яса-лышы | 1 | | | Рәвешләрнең ясалышлары ягыннан тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә төрләргә бүленүе. Кушма рәвешләрнең кушылып, парлы рәвешләрнең сызыкча аша язылуы. Тезмә рәвешләрнең ике яки берничә сүздән тезелеп ясалулары. | Диктант - 7 мин | |
| 46. | | Рәвеш дәрәҗәләре | 1 | | | Рәвеш дәрәҗәләре: төп, чагыштыру, артыклык дәрәҗәләре. Сыйфатлар белән уртаклыгы. | | |
| 47. | | Рәвешләрнең мәгънә төркемчәләре. | 1 | | | Рәвешләрнең билге һәм хәл рәвешләренә бүленүе. Билге рәвешләренә саф, охшату-чагыштыру, күләм-чама рәвешләре керүе. Хәл рәвешләренә вакыт, урын һәм сәбәп-максат рәвешләре керүе.. | | |
| 48. | | Изложение (контроль) | 1 | | | | Изложение №4 | БСҮ-10 |
| 49 | | Рәвешләргә морфологик һәм морфологик-синтаксик анализ | 1 | | | | | |
| 50. | | Контроль диктант | 1 | | | | Диктант №5 | |
| **21 сәг.<br>4ЧИРЕК** | | | | | | | | |
| **АЛМАШЛЫК** | | | | | | | | |
| 51. | | Алмашлык турында төшенчә | 1 | | | Үзләрен атамыйча гына зат яки предметларга, аларнын билгесе яки санына һәм хәлләренә күрсәтә торган сүз төркеменең алмашлык дип аталуы. | Диктант-10 мин | |
| 52. | | Алмашлыкларның ясалышы | 1 | | | Ясалышлары буенча алмашлыкларның тамыр, ясалма, кушма, парлы, тезмә булулары. Алмашлыкларның җөмләнең теләсә кайсы кисәге (ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл) булып килә алуы. | | |
| 53. | | Сочинение | 1 | | | "Тукай исән, жыры күңелләрдә" исеме астында язу. | Сочинение №4 | БСҮ-11 |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 54. | | Алмашлык төркемчәләре. Зат алмашлыклар ы | 1 | | | Мәгънәләре буенча алмашлыкларның җиде төркемгә бүленүе: зат алмашлыклары, тартым алмашлыклары, күрсәтү алмашлыклары, билгеләү алмашчыклары, сорау алмашлыклары, юклык алмашлыклары, билгесезлек алмашлыклар. Зат алмашлыкларының сөйләшүдә катнашучы затларны белдерүләре, килешләр белән төрләнүләре. I һәм II зат алмашлыклары сөйләмдә катнашкан затларны белдерә, берлек һәм күплек санда киләләр, килеш белән төрләнәләр; III зат алмашлыклары ул, алар сөйләмдә катнашмаган, әмма шулар турында сүз барган зат яки предметларны бел-дерәләр, берлек яки күплек санда киләләр. Зат алмашлыкларының килешләр белән төрләнүендә үзенчәлекләр. Гариза язу үрнәге бирү. | | |
| 55. | | Тартым алмашлыклары | 1 | | | Предметның кайсы затка каравын белдергән алмашлыкларның тартым алмашлыклары дип аталулары. Аларның кайбер алмашлыкларга -ныкы, -неке кушымчалары ялганып ясалуы. Тартым алмашлыкларының килеш, сан белән төрләнүе. Аларның җөмләдә ия, хәбәр һәм тәмамлык булып килүе. | Диктант - 5 мин | |
| 56. . | | Күрсәтү алмашлыклары Күрсәтү алмашлык-ларының тартым, килеш белән төрләнеше | 1 | | | Күрсәтү алмашлыкларының затка, предметка һәм шулай ук предмет яки эш-хәл билгеләренә күрсәтүе. Күрсәтү алмашлыкларының, исемне алыштырып килгәндә, килеш, тартым, сан белән төрләнүе; җөмләдә ия, тәмамлык, хәбәр булып килүе.<br>Күрсәтү алмашлыкларының предметның билгесенә яки рәвешенә ишарә иткәндә килешләр белән төрләнмәве, җөмләдә аергыч яки хәл булып килүләре. Күрсәтү алмашлыклары тартым белән төрләнгәндә аларга 3 зат кушымчасы ялгану. | | |
| 57. | | Изложение | 1 | | | | Изложение №5 | БСҮ- 12 |
| 58. | | Сорау алмашлыклары | 1 | | | Предметны, затны, билгене, санны яки рәвешне ачыклау максатыннан кулланылган алмашлыкларның сорау алмашлыклары дип аталулары. Сорау алмашлыкларынын килешләр белән төрләнүе. | Диалог төзү | |

| | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 59. | | Билгеләү алмаш-лыклары | 1 | | | Билгеләү алмашлыкларынын гадәттә затларны, предметларны гомумиләштереп белдерүләре. Аларнын исемне ачыклап аергыч булып килгәндә төрләнмәүләре. Үзләре ачыклаган сүз урынына килгәндә килеш, тартым белән төрләнүе, берлектә һәм күплектә килүләре. Үз алмашлыгының өч затка да каравы һәм тартым, килеш белән төрләнүе, берлектә һәм күплектә килүе. | Тәрҗемә итү | |
| 60 | | Билгеләү алмаш-лыкларының килеш белән төрләнеше | 1 | | | Билгеләү алмашлыкларынын килешләр белән төрләнешен үзләштерү. | | |
| 61. | | Хикәя "9 Май - Җиңү бәйрәме" | 1 | | | | Хикәя | БСҮ-13 |
| 62. | | Билгесезлек алмашлыклары | 1 | | | Зат яки предметның, билге, рәвеш, сан һәм кайбер хәлләрнең билгесезлегена ишарә итүче алмашлыкларның билгесезлек алмашлыклары дип аталуы. Билгесезлек алмашлыкларынын сорау алмашлыкларына әллә сүзе яки -дыр. -дер, -шыр, -тер кисәкчәләре гушылып ясалулары. | Тәрҗемә итү. | |
| 63 | | Юклык алмашлыклары | 1 | | | Затның, предметның, билге, рәвеш, сан яки хәлнең кире кагылуын, инкарь ителүен белдергән алмашлыкларның юклык алмашлыклары дип аталуы. Аларнын сорау алмашлыклары алдына һич яки бер сүзләрен кую юлы белән | Диктант-7 мин | |
| 64 | | Алмашлыкларны кабатлау | 3 | | | Алмашлыкларга морфологик-синтетик анализ ясый белү. Алмашлык темасы буенча өйрәнгәннәрне ныгыту. | Гариза язу. | БСҮ -14 |
| 65. | | Сочинение | 1 | | | | Сочинение №5 | БСҮ -15 |
| 66 | | 6 нчы сыйныфта үткәннәрне | 3 | | | 6 нчы сыйныфта үткәннәрне кабатлау, гомумиләштерү. | | |
| 67. | | Контроль диктант | 1 | | | | Диктан №6 | |
| 68. | | Йомгаклау дәрес | 1 | | | | | |
| | | сәг. | | | | | | |
| | | 68сәгать | | | | | | |

Ел буенда  үткәннәрне кабатлау

## 6 нчы сыйныфны тәмамлаган татар балалары (рус мәктәбендәге) үзләштерергә тиешле белем-күнекмәләр

- телдән һәм язма сөйләм, диалог һәм монолог, текст төшенчәләрен аңлау һәм гамәлдә дөрес куллану;
- тыңлап аңлау һәм уку буенча телдән һәм язма рәвештә хабәр ителгән мәгълүматны аңлау;
- сөйләү һәм язуда татар әдәби теленең төп нормаларын саклау;
- татар теленең фонетик, лексик системаларын һәм грамматик төзелешен үзләштерү;
- сүзләрне төзелеше һәм ясалышы буенча тикшерә белү;
- сүз төркемнәренә морфологик анализ ясау;
- сорауларга тулы һәм дөрес итеп җавап бирү;
- текстның планын төзү, тәкъдим ителгән текстларны рус теленнән татар теленә һәм татар теленнән рус теленә тәрҗемә итү.